

Матбугат йортында Мордовия сәламәтлек саклау министры Олег Маркин белән пресс-конференция vтте. Ул республикабызда Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының 2019 елның 13 мартындагы «Олы яшьтәге халыкның аерым төркемнәренә профилактик медицина тикшерvен һәм диспансеризация vткәрv тәртибен раслау турында»гы 124н номерлы боерыгы» нигезендә vтә торган диспансерлаштыру турында сөйләде.
Быелдан башлап Россиядә Президентыбыз Владимир Путин инициативасы белән «Сәламәтлек саклау» проекты гамәлгә ашырыла. Аның максаты - vлvчеләр санын киметv һәм халыкның гомер озынлыгын арттыру. Диспансерлаштыру - бу бурычларга ирешvнен төп коралы. Ул Мордовиядә 2013 елдан бирле vткәрелә. Яз коне диспансерлаштыруның яңа ка-гыйдәләрен билгеләvче югарыда әйтелгән боерык vз көченә керде. Хәзер медицина тикшерvе сыйфатлырак булачак.      Диспансерлаштыруның максаты - онкологияне, йөрәк-кан тамырлары авыруларының, шикәр диабетының, сулыш органнары авыруларының һәм ашкайнату системасының иртә стадияләрен ачыклау, дип очрашуда искәртте Олег Маркин.
«Авыруны башлангыч стадиядә ачыклаганда, безгә, табибларга, бу патологиядән тулысынча азат итv өчен, аз көч куярга кирәк булачак һәм пациентка дәвалануны җиңелрәк vтәргә ярдәм итәчәкбез», - ди Мордовия сәламәтлек саклау министры чыгышында.
Регионыбызда диспансерлаштыру атналарга сузыла иде, ә быелгысы - ике этапта уза һәм аз вакыт эчендә vтәргә мөмкин. Ул vз эченә: анкеталаштыру, тән массасы индексын исәпләv, кан басымын vлчәv, кан басымын гомуми анализлау, холестерин дәрәҗәсен тикшерv һәм глюкоза дәрәҗәсен билгеләv, йөрәк-кан тамырлары куркынычын билгеләv, флюорография, ЭКГ, кvз эчендәге басымны vлчәv, хатын - кызлар өчен-табиб акушер-гинеколог тарафыннан карауны ала. Кыскасы - кырык яшьтән олкәнрәк кешеләр өчен онкопатологияләрне иртә ачыклауга юнәлдерелгән тикшеренvләр комплексы өстәлә. Хатын-кызларда сөт бизләренен яман шешен иртә диагностикалау өчен маммография һәм акушер-гинекологның тикшерvләре, аналык муенсасыннан-шейкасыннан (яше буенча), мазок алына, ир-атларда (45, 50, 55, 60, 64 мәни бизенен яман шеш авыруын диагностикалау өчен простат-специфик антигенга (ПСА) кан тикшерелә, эчәклек яман шешен иртә диагностикалау өчен (40-64 яшь) калны, ашказанының яман шешен скринингглау һәм башка тикшерv юллары белән vткәрелә.

Аннан соң кабул итүне ФАП фельдшеры, табиб-терапевт яисә гомуми практика табибы үткәрәләр. Барлык тикшерүләр нигезендә сәламәтлекнең торышы турында нәтиҗә ясала. Әгәр диспансерлаштыру үтүчененң диагнозы төгәлләштерүне һәм өстәмә тикше ренүләр сорый икән, шул очракта икенче этап башкарыла.
Диспансерлаштыру беркетелгән урын буенча поликлиникада бушлай үткәрелә. Страховкаланган 18-39 яшьтәге гражданнар диспансерлаштыруны өч елга бер, ә профилактик карауны елга бер тапкыр уза алалар. Кырык яшьтән олы гражданнар өчен диспансерлаштыру ел саен үткәреләчәк.
Диспансерлаштыруны эштән буш вакытта - кичке сәгатьләрдә яки шимбә (суббота) көнне дә узарга мөмкин. Тагы бер яңалык ишеттерде министр. Беренче гыйнвардан Хезмәт кодексына хезмәткәрләрнең сәламәтлеген яклауга юнәлдерелгән һәм диспансеризация узу кагыйдәләренә кагылышлы төзәтмәләр үз көченә керде. Хәзер Закон эш бирүчегә, диспансеризация узу өчен, хезмәткәргә бирелгән өстәмә ял көнендә (өч елга бер тапкыр) уртача хезмәт хакын саклап калуны йөкли. Шулай итеп, 18-39 яшьлек кешеләр өч елга бер көнгә эштән азат ителергә хокуклы. Пенсиягә биш ел калган кешеләр, шулай ук эшләүче пенсионерлар ике түләүле көнгә хокук алдылар, өстәвенә, ел саен. Көн буена поликлиникага китсәң өчен, хезмәткәр эш бирүчегә гариза бирергә һәм аның белән тикшерү датасын килештерергә тиеш. Шулай, «пенсия яшендәге» кешеләр - елына бер тапкыр ике эш көненә эштән азат ителергә хокуклы.
«2019 елда Мордовиядә диспансерлаштыруны 449 мең кеше узарга тиеш, яртысы (51%) инде моны эшләде», - диде Олег Маркин. Тагы ул диспансерлаштыру – җитди эш һәм медицина учреждениеләре хезмәткәрләренең бу процедурага салкын карашына юл куймаячакбыз, дип ышандырды.

**Наилә Насырова**